15 октябь, 2013ел
№5

Алга, белеем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем мәктәбе укучыларының нәфис басмасы

## Әлеге санда:



Мәктәп дәрьясында…
(2 нче бит)



Тарих сәхифәләре (2 нче бит )



Сау бул, Универсиада – 2013! (3 нче бит)



Илһам канатында (4 нче бит )

## Белем көне

И мәктәбем!
Зур хыяллар белән,
Кыңгыраулар белән дәшәсең.
Мең кат сагынып,
Мең кат сагындырып,
Каршы ала безне бу мәктәп –
Укытучының елмаюы белән,
Уку елы белән бүләкләп.

Беренче сентябрь – ул Белем бәйрәме. Шулай да беренче кыңгырау тавышы, дулкынланулар, чәчәк бәйләмнәре, ак бантлар һәм, әлбәттә, сыйныф сәгатьләре. Бу көн мәктәп бусагасын беренче тапкыр атлап кергән нәни дусларыбыз өчен көтеп алынган көннәрнең берсе. Чөнки ул аларны белем иленә алып керәчәк.

Беренче сентябрь – уку елы башлану көне. Иң беренче чиратта ул укучылар, укытучылар, студентлар өчен әһәмиятле. Белем бәйрәменең иң зур кунаклары – беренче



Югары уку йортларында исә, мәктәптәге кебек линейкалар булмаса да, әлеге көннең бәйрәм икәнлеген беркем дә онытмый.

Без сезне барыгызны да уку елының башлануы белән тәбрик итәбез. Укуыгызда уңышлар, олимпиадаларда беренче урыннар алуыгызны теләп калабыз.

Тормышта белемнең әһәмиятен онытмыйк. Һәр гаиләдә белемнең, зирәклекнең урыны алга куелсын иде.

**Диләрә Мостафаева,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

## Мәктәп хәбәрләре:

1. **Мәктәбебезнең 35 еллык юбилее күңелләрдә озак сакла199ныр.**
2. **Барлык фәннәр буенча Бөтенроссия олимпиадаларның мәктәп туры үткәрелде. Укучыларыбыз актив катнашты. Җиңүчеләр шәһәр турында катнашачаклар.**
3. **Мәктәптә «Дан минутлары» дигән конкурс бара. Тиздән җиңүчеләр билгеле булачак.**
4. **«Көз бүләкләре» дигән бәйрәм зур күтәренкелек белән үтте.**
5. **Клара Хәйретдинованың иҗат кичәсеннән рухи баеп кайттык.**

## Күренеклк татар әдибе - Абдулла Алишка 105 яшь


Абдулла Алиш тумышы белән Татарстанның хәзерге Спас районына кергән Көек авылыннан. Кечкенә Алиш 8 яшеннән үк үз көнен үзе күрә башлый – Ямбакты мәдрәсәсенә укырга керә. 1918-1920 елларда Бураково авылы мәдрәсәсендә укып йөри. Нәкъ шушы елларда ул көндәлек алып бара башлый, шигырьләр, хикәяләр, дини парчалар язу белән мавыга.

Казан жир төзү техникумын тәмамлагач, Алиш берара Минзәлә шәһәрендә яшәп ала, мелиоратор булып эшли. 1931 елда яшь шагыйрьнең “Отряд флагы” дип исемләнгән беренче шигырь китабы дөнья күрә. 1931-1933 елларда Алиш Казанда төзелеш оешмаларында эшли, 1934 елда “Техника” журналына җаваплы секретарь булып эшкә күчә һәм бөтен көчен журналистикага һәм әдәби иҗатка багышлый.

Абдулла Алиш әдип буларак, бигрәк тә балалар язучысы буларак 1937-1941 елларда “Пионер каләме” журналында җаваплы секретарь булып эшләгән елларда ачыла.

1941 елның август аенда А. Алиш фронтка китә, шул ук елның октябрь аенда әсиреккә төшә, 1944 елның мертында үлем җәзасына хөкем ителә.

А.Алиш фронтка әкиятче булып китә, туган иленә патриот-шагыйрь булып әйләнеп кайта. Бүгенге татар баласын әдәбиятта иң беренчеләрдән булып Алиш һәм Тукай шигырьләре, әкиятләре каршы ала. Алиш бүген дә безнең белән, ул бүген дә безгә кирәк









Абдулла Алишны киң катлам укучыларыбыз Муса Җәлилнең тоткынлыктагы көрәштәше, каләмдәше һәм якын дусты буларак беләләр. Аның «Ана әкиятләре» 1941 елдан бирле туктаусыз татар һәм рус телләрендә басылып килә. Татарлардан кем генә аларны тыңлап үсмәгән һәм, үзе ата яки ана булгач, үз балаларына укымаган! Шуңа да әлеге йөз еллык юбилей көннәрендә без бу батыр көрәшче һәм талантлы язучыны яңадан искә төшерәбез һәм аның якты образын тулырак итеп күз алдына китерәбез

Гаҗәп матур күңелле кеше иде ул... «...Урта буйлы, киңчәрәк гәүдәле, карасу-ал йөзле, кара күзле, кара кашлы, шундый ук чемкара чәчле, ияк очында бармак басым урыны батыбрак торган ягымлы егет минем хәтеремдә бик акыллы һәм тыйнак кеше сыйфатында саклана. Җәйләрен күбрәк шакмаклы шотландка күлмәктән, кышларын күн курткадан йөрүе исемдә...»

**Мирсәй Әмир, язучы**

«Минә ул — тыйнак кына, атылыпсугылып кешедән алга чыкмыйча, иптәшен бүлдермичә, игътибар белән генә тыңлап тора. Шул арада, барлык тешләрен күрсәтеп, иркен генә көлеп җибәрә, һәм син басынкы, кыюсыз кебек күренгән Алишны бөтенләй икенче яктан таный башлыйсың. Эре сөякле, тере һәм хәрәкәтчән бу кешенең үткен сүзләре, кинаяле карашлы һәм шат күңелле икәнен белергә күп вакыт кирәкми. Ул гади генә вакыйга турында сөйләп китә... Әйтик, берәү редакциягә шигырь китергән. Шул гади генә хәбәргә Алиш мәгънәле генә бер сүз кыстыра, һәм шул сүзнең тапкырлыгы сине хәйран калдыра, кинәт көлү кабындырып җибәрә...».

**Гази Кашшаф, тәнкыйтьче**

## Универсиада истәлекләре

Универсиада уты планетаның төрле почмакларында яшәүче студентларның бердәмлеген, дуслыгын һәм тынычлыкны символлаштыра. 6 нчы июльдән алып 17 нче июльгә кадәр Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада уты эстафетасы – Студентларның Бөтендөнья Уеннары тарихында тиңе булмаган вакыйга булып узды.

Әлеге ике атна эчендә без, мәктәп укучылары (10 нчы һәм 11 нче сыйныфлар), укытучыларыбыз белән шәһәр волонтерлары булдык. Шәһәребезгә төрле илләрдән килгән кунакларны каршы алып, аларның сорауларына җавап бирергә тырыштык. Безгә, ягъни волонтерларга, махсус спорт киемнәре, бейджиклар бирелде. Шуңардан тыш, һәр көнне Макдоналста бер тапкыр ашау мөмкинлеге дә бар иде.

Һәр көнне өч сменага бүленеп эшләдек. Беренче сменага килсәң, иртәнге зарядка ясау, йокылы килеш, көлкеле фоталарга төшүләр булды. Иң авыры икенче һәм өченче сменага була иде, чөнки бу вакытта уеннар башлана. Тамашачыларның саны күпме дип сорасагыз, чиратның озынлыгын күрү генә дә җитә.

Универсиада вакытында күп кенә яңа кешеләр белән таныштык. Күп уеннарны бушка карый алдык. Шуның өстенә шәһәр буенча йөри торган транспорт та волонтерларга бушка иде бит.





Волонтерларны бүләкләү тантанасында сәгать, рәхмәт хатлары һәм Барс Юни уенчыклары белән бүләкләндек.

Универсиаданың Казанда үтүе - безнең өчен зур горурлык! Дөньяда нинди генә зур шәһәрләр юк. Шуларны узып, Казаныбызның Универсиада уздыру хокукы алуы - әйтеп бетерә алмаслык куаныч! Димәк, Татарстан башкаласы үзен яхшы яктан күрсәтә ала торган дөньякүләм әһәмияткә ия спорт шәһәре.



Киләчәктә дөньяга танылган спортчылар безнең Казаныбызда күпләп үсеп чыгар әле. Шуның өстенә төзелгән спорт объектларында Европа дөнья чемпионатлары да уздырып булачак бит..

Мин Татарстаныбызның, Казаныбызның киләчәге матур, шөһрәтле булыр дип ышанам.

**Самат Сөләйманов,**
**11 нче сыйныф укучысы**

# Илһам канатында



## Җәйге универсиада

6 нчы июльдән алып, 17 нче июльгә кадәр Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада уеннары булып узды. Шәһәребез әлеге уеннарга бик әйбәт итеп әзерләнде: күп итеп спорт объектлары һәм юллар төзелде, матур чәчәкләр утыртылды. Мин ачылу һәм ябылу тантанасын телевизордан карадым. Регби, ишкәк ишү ярышларына гаиләбез белән бардык. Универсиада паркында ял итеп кайттык. Түбәтәйле, чәк-чәкле халкыбыз бу көннәрдә күтәренке күңел белән яшәде. Чит ил кунакларына бик игътибарлы булды.

Универсиаданың Казанда үтүе яхшыга гына: хәзер Татарстанны бөтен галәмдә беләләр.

**Илгиз Якубов,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

## Беренче сентябрь

Беренче сентябрь – уку бәйрәме. Балалар бу бәйрәмне, күңелле җәйге яллардан соң, көтеп алалар. Әлеге көнне бөтенесе дә матур киемнәрен киеп, кулларына чәчәк бәйләмнәрен тотып, мәктәпкә киләләр. Бу көнне, ниһаять, укытучылар үзләренең укучылары белән очрашалар.

Укытучылар һәм өлкән сыйныф укучылары бәйрәмдә линейка оештыралар. Белем бәйрәме турында төрле, матур шигырьләр укыйлар. Укытучыларга аллы-гөлле чәчәк бәйләмнәрен тапшыралар.

Балаларның ата-аналары да бу көнгә әзерләнәләр: балаларын матур киендереп, букетларны әзерләп, акыллы булып үсүләрен теләп, озатып калалар.

**Ләйлә Магеррамова,**
**6 нчы М сыйныфы укучысы**



## Казан

Казан шәһәре – Рәсәйнең иң матур шәһәрләренең берсе. Казан – яшьләр шәһәре. Бездә бик күп югары уку йортлары, студентлар. Шуңа күрә дә Универсиадага әзерлек вакытында шәһәрдә бик күп спорт комплекслары төзелде. Бик матур, уңайлы юллар төзеделәр. Без яши торган йортларны яңарттылар. Шәһәр танымаслык булып үзгәрде. Бөтен җирдә аллы-гөлле чәчәкләр утырттылар.

Универсиада безнең Казанны бөтен дөньяга танытты. Мин Казанда яшәвем белән горурланам.

**Радик Идрисов,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**

**"Моңы бар көйләп күрсәтер, теле бар сөйләп күрсәтер"**

**Мөҗәһит Әхмәтҗанов**

Татар теле дәресләрендә без күбрәк бер-беребезгә ярдәмләшеп эшлибез. Моның өчен аерым командалар булдырабыз. Шуңа күрә сыйныфыбызда ялкауланып, шыпырт кына качып эндәшми калган укучылар хәзер юк. Төрле күнегүләрне без җитез генә башкарып чыга алабыз, чөнки төркемдә эшләү күпкә җиңелрәк, шул ук вакытта җаваплырак та. Барысын да үзебез хәл итәбез. Шуның белән укытучыбызга да эш кими: командада утырган һәрберебезгә бәя биреп, билге куябыз. Күнегүләрне дә күбрәк үзебез тикшереп, бәялибез.

Килешәм: "Максатка ирешү өчен бер генә нәрсә кирәк: алга бару", - дигән Оноре де Бальзак. Телне өйрәнү, аны үзләштерү, билгеле булганча, бик катлаулы, иҗади эш. Аның нигезендә өйрәтүчегә механик рәвештә иярү түгел, бәлки актив танып- белү эшчәнлеге ята. Безнең төп максатыбыз – татарча аңлау, сөйләшергә өйрәнү. Укытучыбыз Исаак Ньютонның әйткән фикерен исәптә тотып эшли, ягъни "Фәнне өйрәнгәндә, кагыйдәләргә караганда мисаллар файдалырак" . Шуңа күрә сөйләм теленә һәм иҗади фикерләүгә игътибар күбрәк бирелә.

**Илья Валеев,**
**Эмиль Инсафутдинов, 5 е-м сыйныфы**

## Җәйге яллар

Рәхәт тә соң җәй көннәре! Өстеңдә — җиңел кием, аягыңда да кышын өстерәгән киез итек я булмаса авыр табанлы ботинкалар түгел. Кояш белән бергә торып, мәктәпкә йөгерәсең дә юк. Ятасың иркәләнеп йомшак юрган астында. Җәен әле аның йокысы да тизрәк туя. Югыйсә кыш буе хыялланасың: эх, җәй генә җитсен, туйганчы бер йоклар идем, дисең. Инде укулар бетеп, күпмедер вакыт узуга ук, көнеңне, сәгатеңне йокыга гына әрәм итәсең килми башлый. Күңел гел каядыр җилкенеп, ашкынып тора.

Мин исә, җәйге ялларымны авылда: әби белән бабам янында уздырырга яратам. Җәй буе алар белән нәрсә генә эшләмибез. Бабай белән урманга да барабыз. Анда без гөмбәләр, дару үләннәре, каен җиләге, җир җиләкләрен һәм чикләвекләр җыябыз.

Җәй көнне бакча эшләре дә кимеп тормый: чүп үләннәрен утаумы, бәреңгене өюме, сулар сибәргә дисеңме – барысын да эшләргә кирәк.

Печән вакыты җиткәч, печән әзерли башлыйбыз. Ул кипкән печәннең хуш исе!


Дусларым белән дә уйнарга вакыт кала. Велосипедта узышып та йөрдек. Туйганчы су да коендык бергәләп. Кояшның эссесе сүрелгәч, балык тотарга да бардык. Малайлар белән анда да балыкларны узышып тоттык. Иң күп балык тотучы – мин үзем булдым. Иптәшем исә, алабуга балыкларын гына тотты.

Җәй рәхәт. Җәең авылда узса, аеруча рәхәт. Ныгып, тазарып, үзең дә яшелчә кебек өлгереп, мәктәпкә киләсең.

Авыл балаларының күбесе каникулда беркая да китми. Китсә дә, тизрәк кайтып җитә. Колыныма ул-бу булмаганмы, каз-үрдәкләрне саклаучы бармы, сыер-фәлән, кирәкмәгән ризык ашап, ялгыш чирләп китмәсен, дип, гел борчылып тора бит ул.

Мин үзем бөтен каникулларны да авылда уздырам. Шәһәр һавасын үскәч тә су-ларга өлгерербез әле, дим.

**Илназ Гиматдинов,**
**6 нчы М сыйныфы укучысы**



### Беренче укытучым

Хәрефләр яздырдың,
Тездердең иҗекләр.
Белемнең иленә
Ачылды ишекләр.
Кырыс та, назлы да,
Таләпчән, сөйкемле,
Укытучым, син минем
Әнием шикелле.
Сораулар яудырсак,
Җавабын табасыз.
Хөрмәтле кеше, Сез,
Сездән көч алабыз.

**Алсу Әхмәдуллина,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

### Укытучым

Күп әйтсәм дә,
Күп язмамын,
Сез укытучым – галим!
Бик яхшы Сез, иң уңган Сез!
Иң гадел кешедер Сез!
Әлифба хәрефләрен дә,
Тик Сез өйрәткәч белдем,
Беренче шигыремне язып,
Иҗат иленә кердем!
Каләм тотып кулыма;
Беренче сүземне башлыйм
Сезне хөрмәт иткән өчен
Мин бик тырышып укыйм!

**Алсу Әхмәдуллина,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**



## Быел безнең мәктәпкә – 35 ел!

**Шушы елларда мәктәп белән Г.Ф.Журавлева һәм Т.В.Пашкова идарә иткән булсалар, алар хәзерге вакытта лаеклы ялда.**

**3 нче ел мәктәп белән Әлфия Гусмановна Урманчеева идарә итә. Аның җитәкчелегендә күп үзгәрешлр булды: капиталь ремонт ясалды, профильле сыйныфлар ачылды, мәктәп музее да яңартылды. Хәрби-патриотик тәрбиягә дә зур игътибар бирелә—кадет сыйныфлары дабарлыкка килде.**

**Безнең мәктәптә 35 ел буе эшләгән укытчыларыбызга берничә сорау бирергә булдык**:

**-Исәнмесез, Марзия Зәкиевна! Быел мәктәпнең юбилее, мәктәпкә - 35 ел! Мәктәпнең ачылганнан соң нинди үзгәрешләр булды?**

-Үзгәрешләр бик күп булды. Мәктәп ачылгач та балалар күп иде. Аннан соң аларның саны 2600 хәтле җитте!

**- 35 ел буена мәктәптә эшләп, күңелегездә калган иң кызыклы вакыйга турында сөйләгез әле!**

-Мин бу мәктәптә эшли башлаганда, миңа 28 яшь генә иде. Балалар белән эшләгән һәр көн, үзе бер кызыклы дөнья инде ул!

**- 80 нче еллардагы балалар белән хәзерге балалар нәрсә белән аералар?**

- Ул вакыттагы һәм хәзерге балалар да, һәрберсе яхшы. Һәр чорның үрнәк укучылыры да, тәртипсезләре дә була инде ул.

**-Әлеге мәктәпкә нинди яңалыклар кертер идегез?**

- Мәктәбебез лицей булсын иде. Ул статусны алгач, һәр укучы без менә әлеге лицейда укыйбыз дип, горурланып йөрсеннәр. Без аңа лаек!

**- Яшь укытучыларга нинди теләкләрегез бар?**

- Зур иҗади уңышлар, бәхет, сәламәтлек телим. Алар балаларны, балалар аларны яратып, яңа үрләр яуласыннар иде!

**- Исәнмесез, Таһир Гайсович, быел безнең мәктәпнең юбилее, мәктәпкә 35 ел. Мәктәпнең ачылган көне белән чагыштырганда нинди үзгәрешләр булды?**

- Мәктәбебез үзгәрде, ремонт ясалды, матур булды.

**- Сез 35 ел буе бары тик бу мәктәптә генә эшләдегезме?**

- Юк, мин 139 нчы һәм 150 нче мәктәпләрдә эшләгән идем. Ләкин минем 78 нче мәктәбем иң яраткан мәктәбем.

**- Бу мәктәптә эшләгән вакытта булган күңелле вакыйга турында сөйләгез әле?**

- 80 нче елларда без балалар белән хезмәт лагерында булдык. Мин яшь идем, әле ул вакытта миңа 29 яшь. Мишә күлендә балык тоткан идек.

**- Без сезнең мәктәп директоры булып эшләгәнегезне беләбез. Мәктәп директоры булып эшләү авырмы?**

- Мәктәп директоры булу иң авыр эш. Бөтен мәктәп синең җилкәңдә, һәр бала өчен җаваплы буласың.

**- Хәзерге яшь укытучыларга нинди теләкләрегез бар?**

- Түземлек, түземлек һәм тагын бер кат түземлек теләр идем. Балаларны яратмаган кеше мәктәпкә эшләргә килми инде ул, ләкин шулай да аларны яратсыннар иде. Балалар шаяртырга бик күп яраталар. Шул шаяртуларны аңлый белсеннәр иде.

**- 80 нче еллардагы балалар белән хәзерге балалар нәрсә белән аералар?**

- 80 нче еллардагы балалар сәламәт балалар булган. Алар физкультура дәресләрен яратып йөри торганнар иде, ә хәзерге балаларга белмим нәрсә кирәк.

**- Әлеге мәктәпкә нинди яңалыклар кертер идегез?**

- Балаларны эстетикага өйрәтер идем. Эстетика фәне керсен иде. Мисал өчен ашханәдә утырганда пычак, чәнечке белән кулланып ашый белсеннәр иде. Балаларны, минемчә матурлыкка өйрәтергә кирәк, матур гадәтләр алар өчен ят булмасыннар иде.

**- Исәнмесез, Татьяна Николаевна, быел безнең мәктәпнең юбилее, мәктәпкә 35 ел. Мәктәпнең ачылган көне белән чагыштырганда нинди үзгәрешләр булды?**

- Үзгәрешләр бик күп булды инде. Укыту системаларына килгәндә: БДИ һәм ГИА лар кертелде. Укытучыларга күп белергә, үз өстендә эшләргә кирәк. Минем уйлавымча, хәзерге дәресләр күпкә кызыграк үтәлер, чөнки техника ягыннан уңайлы, күңелең нәрсә тели шуны күрсәтеп була. Мәктәбебез исә, матурланды, зур ремонт эшләре эшләнелде.

**- Бу мәктәптә эшләгән вакытта булган күңелле вакыйга турында сөйләгез әле?**

- Балалар белән һәрвакыт кызык була инде. Күңелле вакыйгалар да гел булып тора, күңелсезләре дә була шунда. “Соңгы кыңгырау”, “Белем бәйрәмнәре” – барысы да зур вакыйгалар.

**- 80 нче еллардагы балалар белән хәзерге балалар нәрсә белән аералар?**

Ул вакыттагы балалар өчен “Пионер лагерьлары” эшләп тора иде. Балалар бер-берсе белән аралашып, матур гына уйнап үсә торганнар иде. Ә хәзерге балалар өчен интернет, телефон кирәк. Тере аралашуның әһәмиятен дә күрмәүчеләр аз түгел.

**-Мәктәпкә нинди яңалыклар кертер идегез?**

-Менә балаларга иң беренче чиратта теләгем шул: күбрәк матур әсәрләр укысыннар иде. Балалар кечкенә вакыттан ук, киләчәктә кем булачакларын аңлап үссеннәр. Тәнәфес вакытларында тәртипсезләнеп чабып йөрмәсеннәр өчен спортзаллара уйнарга рөхсәт булсын иде. теннис өстәлләре куелып теннис уйнасыннар иде. Түләүсез ашау да булдырылсын иде. Безнең мәктәпнең даны бөтендөньяга таралсын иде. Мәктәбебезнең ишегалды аллы-гөлле чәчәкләр белән күмелеп торсын иде.

**- Яшь укытучыларга нинди теләкләрегез бар?**

- Алар иң яхшы һөнәр сайлаганнарын белеп торсыннар. Тәҗрибәле укытучылар белән киңәшләшеп эшләсеннәр иде.


**Әңгәмәне әзерләделәр:**
**Г.Батталова, А.Әхмәдуллина**

# Җәйге мизгелләр!





































## Сингапур курслары

Җәй көне безнең мәктәптән: А.Л. Ренатовна, А.Н.Сәгдеева, Н.А.Приходько, Э.Ш. Хөснетдинова Сингапур курсларында укыттылар. Әлеге курслар Казан шәһәренең 19 нчы һәм 171 нче мәктәпләрендә үттеләр. Республика методистларын укытып, безнең коллегаларыбыз да зур тәҗрибә тупладылар.



## «Татар егете» конкурсы

2013 нче елның 17 нче октябрендә "Татар егете" шәһәр бәйгесенең районда йомгаклау туры үтте. Анда безнең мәктәпнең 10а сыйныфы укучысы Булат Мусин матур биюе, сәхнә осталыгы, оригиналь жанрда ( цирк номеры) сокландыргыч чыгыш ясавы белән аерылып торды. Нәтиҗәдә, ул "Иң оста егет" номинациясендә җиңеп чыкты.

Әлеге конкурста 9 мәктәптән егетләр көч сынаштылар.



Икенче турга үткән балалар барысы да талантлы, номинацияләрне билгеләү дә җиңел түгел иде.

Булат! Сине чын күңелдән җинүең белән тәбрик итәбез! Зур уңышлар, шатлыклар, сәламәтлек телибез!

**Алсу Сәдыйкова, 10 нчы А сыйныфы укучысы**

## Теләкләр

**78 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары туган көннәрен билгеләп үтүче**



**Зыкова Маргарита Григорьевна**
**Яруллин Эльмир Илсурович**
**Гараева Аида Абдулловна**
**Корочкина Елена Анатольевна**
**Семенова Лидия Ивановна**
**Котова Ирина Валеоьевна**
**Шарапова Лариса Генадьевна**

**Киләчегегез якты, юлларыгыз киң, бәхетегез гомерле, тормышыгыз мул , уңышларыгыз зур булсын!**

*Ихлас күңелдән юллыйбыз*
*Иң-иң изге теләкләр:*
*Озын булсын гомерләр*
*Тыныч булсын күңелләр !*



**Мөхәррирләр:** С.Сөләйманов, Д.Вәлиева, Л. Садыков, Г.Батталова, Р. Идрисов, З. Ибрагимова, Я. Илгиз, А.Әхмәдуллина, Д.Мостафаева
**Консультант:** Л. И. Исмаилова

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс 268-58-61
E-mail: school_7878@mail.ru S78kzn@edu.tatar.ru
Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин: https://edu.tatar.ru/priv/school78.htm/page813169.htm
Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз: lyutsiya_906@mail.ru

Мәктәбем минем